| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ<br>РАЙОН<br>СОВЕТ ГОРОДА КУКМОР<br>422110, г. Кукмор, ул. Ленина, 15 | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>КУКМАРА ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ<br>422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15 |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

21 июнь, 2024 ел № 13

Кукмара шәһәре Советының 2018 елның 05 июнендәге 12 карары белән расланган Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү шартлары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексы, «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, рәис урынбасарларына, аудиторларга, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Кукмара шәһәре Советы карар бирде:

1. Кукмара шәһәре Советының 2018 елның 05 июнендәге 12 карары белән расланган Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү шартлары турында нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) (2022 елның 19 декабрендәге 31 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Нигезләмәнең 2 бүлегендәге 2 пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль хезмәткәрләргә муниципаль хезмәтнең биләгән муниципаль вазыйфасына карап, авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгече вазыйфаи хезмәт хакына калдыксыз бүленә торган күләмдә 13323 сум күләмендә вазыйфаи хезмәт хаклары билгеләнә.»;

б) 2 бүлекнең 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Муниципаль хезмәткәркә вазыйфаи окладның 41 процентыннан артмаган күләмдә айлык акчалата түләүләр түләнә, җирле үзидарә органнары структурасын үзгәртеп корганда, җирле үзидарә органнары структурасы стандартларын кертүгә бәйле муниципаль хезмәткәрне элек биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасыннан түбәнрәк вазыйфаи окладлы муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләп кую очрагыннан тыш, бу очракта акчалата түләү күләмен

исәпләү муниципаль хезмәткәрнең акчалата хезмәт хакын элек ул биләгән вазыйфалары буенча акчалата хезмәт хакы күләменә җиткерүне тәэмин итүне исәпкә алып башкарыла».

а) 2 бүлекнең $8^1$ пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Нормалаштырылмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен айлык компенсация түләү муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи хезмәт хакының 2 процентыннан артмаган күләмдә билгеләнә. Нормалаштырылмаган эш көне булган муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеге җирле үзидарә органының норматив акты белән билгеләнә. Түләүне билгеләү турында карарны җирле үзидарә органы җитәкчесе кабул итә.

г) 3 бүлекнең 1 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) айлык акчалата түләү – хезмәт окладына карата 41 проценттан артмаган күләмдә.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

Кукмара шәһәре мэры С.Д. Димитриев